| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**О комиссии по предварительному рассмотрению предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани**

В соответствии с частью $2^1$ статьи 24 Закона Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» **постановляю:**

1. Образовать комиссию по предварительному рассмотрению предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани.

2. Утвердить Положение о комиссии по предварительному рассмотрению предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани (приложение № 1) и ее состав (приложение № 2).

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
28 августа 2025 года
№ 691

Приложение № 1
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от « 28 » августа 2025 года

№ 691

**Положение**
**о комиссии по предварительному рассмотрению предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани**

1. Настоящее Положение определяет порядок деятельности комиссии по предварительному рассмотрению предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани (далее – Комиссия).

2. Комиссия является коллегиальным органом, образованным в соответствии с Законом Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» для предварительного рассмотрения предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани.

3. Комиссия в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, Федеральным законом от 20 марта 2025 года № 33-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в единой системе публичной власти», иными федеральными законами и нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, Законом Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», иными законами Республики Татарстан и нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

4. Комиссия состоит из семи членов, включая председателя, заместителя председателя и секретаря Комиссии. Состав Комиссии утверждается Раисом Республики Татарстан.

5. Председатель Комиссии:

руководит деятельностью Комиссии;

определяет дату, время и место проведения заседания Комиссии;

утверждает повестку дня заседания Комиссии;

проводит заседание Комиссии;

подписывает протокол заседания Комиссии.

В период отсутствия председателя Комиссии его функции осуществляет заместитель председателя Комиссии.

6. Секретарь Комиссии:

готовит проект повестки дня заседания Комиссии;

организует подготовку и сбор материалов к заседанию Комиссии;

информирует членов Комиссии о дате, месте, времени проведения и повестке дня заседания Комиссии, обеспечивает их необходимыми материалами;

оформляет и подписывает протокол заседания Комиссии;

организует опубликование в средствах массовой информации и размещение на официальном сайте Раиса Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» информации о сборе предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани, сроке и месте внесения предложений;

информирует кандидатов на должность главы муниципального образования города Казани о проведении собеседования на заседании Комиссии.

При отсутствии секретаря Комиссии его обязанности по решению председателя Комиссии могут быть возложены на одного из членов Комиссии.

7. Члены Комиссии принимают личное участие в обсуждении рассматриваемых на заседании Комиссии вопросов и в голосовании. Члены Комиссии обладают равными правами при обсуждении рассматриваемых на заседании Комиссии вопросов.

8. Заседание Комиссии считается правомочным, если на нем присутствует не менее пяти членов Комиссии.

9. Заседания Комиссии оформляются протоколом. Протокол заседания Комиссии подписывается председателем и секретарем Комиссии.

10. Информация о сборе предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани, сроке и месте внесения указанных предложений одновременно опубликовывается в средствах массовой информации и размещается на официальном сайте Раиса Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

11. Срок внесения предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани субъектами, обладающими правом внесения таких предложений, определенными приложением 4 к Закону Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», составляет семь рабочих дней со дня публикации информации о сборе предложений в средствах массовой информации и размещения на официальном сайте Раиса Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

12. Лицо, выдвинутое в качестве кандидата на должность главы муниципального образования города Казани, в течение четырех рабочих дней после окончания срока внесения предложений в соответствии с пунктом 11 настоящего Положения представляет Раису Республики Татарстан заявление в письменной форме о своем согласии быть кандидатом с обязательством в случае его избрания прекратить деятельность, несовместимую со статусом главы муниципального образования, а также документы, предусмотренные

приложением 4 к Закону Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан».

13. Комиссия организует проверку достоверности документов и сведений, представленных в соответствии с пунктом 12 настоящего Положения, в том числе путем направления запросов в соответствующие государственные органы и иные организации в установленном порядке. Срок проведения проверки не может превышать 10 рабочих дней после окончания срока, предусмотренного пунктом 12 настоящего Положения.

14. Кандидаты на должность главы муниципального образования города Казани могут быть приглашены на заседание Комиссии для проведения собеседования.

15. В случае, если в процессе проверки документов и сведений установлена их недостоверность, Комиссия уведомляет кандидата об отклонении его кандидатуры на должность главы муниципального образования города Казани.

16. По каждому из кандидатов, не отклоненных в соответствии с пунктом 15 настоящего Положения, Комиссией проводится рейтинговое голосование, которое представляет собой ряд последовательных голосований членов Комиссии по каждому из кандидатов персонально.

17. По итогам рейтингового голосования Комиссией на рассмотрение Раиса Республики Татарстан представляется не менее двух и не более пяти кандидатов для принятия окончательного решения. Срок представления Комиссией кандидатов на рассмотрение Раиса Республики Татарстан не может превышать 10 рабочих дней после окончания срока проведения проверки, предусмотренного пунктом 13 настоящего Положения.

18. Организационно-техническое обеспечение деятельности Комиссии осуществляется Администрацией Раиса Республики Татарстан.

Приложение № 2
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от « 28 » августа 2025 года

№ 691

**Состав**
**комиссии по предварительному рассмотрению предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани**

| | |
|---|---|
| Сафаров Асгат Ахметович | Руководитель Администрации Раиса Республики Татарстан, председатель Комиссии |
| Нигматуллин Рустам Камильевич | первый заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, заместитель председателя Комиссии |
| Гарипов Ильнур Махмутович | первый заместитель Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан – начальник Управления Раиса Республики Татарстан по работе с территориями, секретарь Комиссии |
| Бадрутдинов Марс Сарымович | начальник Управления Раиса Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики |
| Белов Александр Николаевич | руководитель Департамента государственной службы и кадров при Раисе Республики Татарстан |
| Демидов Виктор Николаевич | главный федеральный инспектор по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Маврина Лилия Николаевна | Секретарь Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне башлангыч карап тикшерү комиссиясе хакында**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясы $2^1$ өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне башлангыч карап тикшерү комиссиясен төзергә.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне башлангыч карап тикшерү комиссиясе турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 28 август
№ 691

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «28» августындагы
691 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне башлангыч карап тикшерү комиссиясе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне башлангыч карап тикшерү комиссиясенең (алга таба – Комиссия) эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне башлангыч карап тикшерү өчен «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән коллегиаль орган.

3. Комиссия үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, «Бердәм гавами хакимият системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә алып бара.

4. Комиссия җиде әгъзадан, шул исәптән Комиссиянең рәисе, рәис урынбасары һәм секретареннан тора. Комиссия составын Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

5. Комиссия рәисе:

Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

Комиссия утырышларын уздыру көнен, вакытын һәм урынын билгели;

Комиссия утырышының көн тәртибен раслый;

Комиссия утырышын уздыра;

Комиссия утырышы беркетмәсен имзалый.

Рәис эш урынында булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

6. Комиссия секретаре:

Комиссия утырышы көн тәртибе проектын әзерли;

Комиссия утырышына әзерлекне һәм кирәкле материалларны җыюны

оештыра;

Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышын уздыру көне, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштерә һәм имзалый;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр җыю, тәкъдимнәрне бирү вакыты һәм урыны турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны оештыра;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатларга Комиссия утырышында әңгәмә уздырылачагы турында мәгълүмат бирә.

Комиссия секретаре эш урынында булмаганда, Комиссия рәисе карары белән аның вазыйфалары Комиссия әгъзаларының берсенә йөкләнергә мөмкин.

7. Комиссия әгъзалары Комиссия утырышында карала торган сорауларга кагылышлы фикер алышуда һәм тавыш бирүдә шәхсән катнашалар. Комиссия әгъзалары Комиссия утырышында карала торган сорауларга кагылышлы фикер алышу барышында бердәй хокукларга ия була.

8. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының ким дигәндә бишесе катнашса, эшчәнлек алып барырга хокуклы була.

9. Комиссия утырышлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия утырышы беркетмәсен Комиссиянең рәисе һәм секретаре имзалый.

10. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр җыю, тәкъдимнәрне бирү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бер үк вакытта массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарыла.

11. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр бирергә хокукы булган, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 4 нче кушымтада билгеләнгән субъектлар тарафыннан мондый тәкъдимнәрне бирү вакыты тәкъдимнәр җыю турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылган һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган көннән җиде эш көне тәшкил итә.

12. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидат буларак күрсәтелгән зат, тәкъдимнәр бирү вакыты тәмамланганнан соң дүрт эш көне дәвамында әлеге Нигезләмәнең 11 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Рәисенә үзенең кандидат булырга ризалыгын белдереп, сайланган очракта, муниципаль берәмлек башлыгы статусында рөхсәт ителмәгән эшчәнлеген туктату йөкләмәсен алып, язма рәвештә

гариза, шулай ук «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 4 нче кушымтада каралган документларны бирә.

13. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 12 пункты нигезендә бирелгән документларның һәм мәгълүматларның дөреслеген, шул исәптән тиешле дәүләт органнарына һәм башка оешмаларга билгеләнгән тәртиптә соратулар юллау ысулы белән дә, тикшерүне оештыра. Тикшерүне уздыру вакыты әлеге Нигезләмәнең 12 пункты нигезендә билгеләнгән вакыт тәмамланганнан соң 10 көннән дә артып китәргә тиеш түгел.

14. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатлар Комиссия утырышына әңгәмәгә чакырылырга мөмкин.

15. Әгәр документларны һәм мәгълүматларны тикшерү барышында аларның расланмаган булуы ачыкланса, Комиссия кандидатка Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына аның кандидатурасы кире кагылуы турында хәбәр итә.

16. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты нигезендә кире кагылмаган кандидатларның һәрберсе буенча Комиссия тарафыннан Комиссия әгъзаларының һәр кандидат буенча шәхсән берничә эзлекле тавыш бирү рәвешендәге рейтинг билгеләү өчен тавыш бирү уздырыла.

17. Рейтинг билгеләү өчен тавыш бирү йомгаклары буенча Комиссия тарафыннан икедән ким булмаган һәм биштән артык булмаган кандидат ахыргы карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Рәисенә карауга тапшырыла. Комиссия тарафыннан кандидатларны Татарстан Республикасы Рәисенә карауга тапшыру вакыты тикшерү уздыруга бирелгән, әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында билгеләнгән вакыт тәмамланганнан соң 10 эш көненнән дә артып китә алмый.

18. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе башкара.

---

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «28» августындагы
691 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне башлангыч карап тикшерү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Сәфәров Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Комиссия рәисе |
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары |
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы, Комиссия секретаре |
| Бәдретдинов Марс Сарыйм улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Белов Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе |
| Демидов Виктор Николаевич | Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор (килешү буенча) |
| Маврина Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре (килешү буенча) |